Участник №86



Бисмиллэhир- рахмээнир- рахим.

Барча галэмнэр Раббысы, куклэрне hэм жирне бар кылучы, золымлыкны hэм нурны яратучы Аллаhе Тэгалэгэ мактауларыбыз булсын! Пэйгамбэребез hэм соңгы булган рэсулебез Мохэммэдкэ салават- сэламнэребез hэм дэ анын гаилэсенен эhеллэренэ сэламнэр булсын!

Мохэммэд Саллэллаhу галэйhи вэ сэллэмнен тормышы турында шигъри поэма.

1. **Тууы hэм балачагы.**

Аллаhынын барлыгына
Берлегенэ ышанам.
hичкемне дэ тудырмаган
hичкемнэн дэ тумаган.

Жир суларнын, дингезлэрнен,
Бар доньянын хужасы.
Раббым бар итмэгэн булса
Юк бит hич ни буласы.

Бар иткэн ул кояшны да,
Зэнгэр кукле галэмнэр.
Жир йозенэ рэхмэт очен
Жибэргэн пэйгамбэрлэр.

Ничэу булган пэйгамбэрлэр:
Бик куп мэгълум тугеле.
Ибраhимнын(г.с.) нэселеннэн
Аллаhынын рэсуле.

Пэйгамбэрлэр аша ингэн
Зэбур, Инжил, Тэураты.
Шул китаптан мэгълум булган
Мохэммэднен(г.с.) туасы.

Сонгы пэйгамбэр булып ул
Доньяларга килэчэк
Ходайнын рэхмэте белэн
Ислам нуры инэчэк.

571нче милади елда
Мохэммэд(г.с.) жиргэ туа.
Ул туганда бик куп кенэ
Галэмэтлэр дэ була.

Энисенен сойлэвенчэ
Карынынннан нур чыккан.
Карыннан чыккан якты нур
Шам сараен яктырткан…

…Мохэммэднен(г.с.) сот анасы
Сахрадагы Хэлимэ.

Имезергэ бала эзлэп
Бу кабилэгэ килэ.

Узлэре ач, дөя ябык,
Бала сотсез тилмерэ.
Мэккэгэ килеп житугэ
Бар да балалар булэ.

Тик аларга ашыкмыйлар
Мөхэммэд(г.с.)- ятим бала.
Атасыздан булэк юк дип
Сайланмыйча ул кала.

( Карында чакта Мөхэммэд(г.с.)
Этисе улгэн була.)
Аллаһ эжерен өмет итеп
Хэлимэ аны ала.

Жэнабел Хак бэрэкэте,
Рэхмэте шулчак инэ.
Кукрэгендэ сөте артып,
Дөялэр дэ сөт бирэ.

Дөялэренэ атланып
Кайтыр юлга чыгалар.
Аллаһның кодрэте белэн
Юлдашларын узалар.

Сарыклар да куп сөт бирэ,
Башкалар аптырыйлар.
Хэлимэ көтуенэ дип
Сарыклар куалыйлар.

Тик нигэдер аларныкы
Ач һэм сөтсез кайталар.
Ходай нигъмэтедер диеп,
һич кенэ уйламыйлар.

Ике яшьтэ Мөхэммэдне(г.с)
Кукрэктэн аералар.
Узлэренэ алабыз дип,
Эминэгэ(р.г.) баралар.

Ана кунэ… тик 4 яшьтэ
Була шундй вакыйга
Уйнап йөргэн чакта рэсул
Жэбраилгэ юлыга.

Жэбраил тотып ала да
Жиргэ сала баланы.
Кукрэген ачып калебтэн
Ала оешкан канны.

Участник № 86



Калебне алтын табакта
Зэм-зэм суында юып.
Кырыйларын берләштерә
Кире урынына куеп…

…Бу хэлдэн сон Хэлимэ дэ
Бик нык куркуга кала.
Эминэгэ Мөхэммэдне ( г.с)
Кире кайтарып бара…

…Уз энисе янында ул
6 яшькэчэ яши.
Ирен зыярэт кылганда
Эминэ бик нык чирли.

Мэккэ-Мэдинэ юлында
Кайтканда вафат була.
Бабасы Габделмоталлиб
Оныгын узенэ ала.

Бабасынын кунеленэ
Кызгану хисе тула.
Уз балаларыннан бигрэк
Оныгы якын була.

Мөхэммэдкэ (г.с) сигез яшьтэ
Бабасы вафат була.
Атасынын туганына
Эбу Талибкэ кала.

Әбу Талиб Мөхэммэдне (г.с)
Бик яхшы тэрбияли.
Аны олылап 40 ел
Гел ярдэм итеп яши.

Мөхэммэдне (г.с) Әбу Талиб
Шамга сәудәгә дәшә.
Рәсулнен тула ул чакта
Төгэл 12 яше.

Бусрага килеп житкәндэ
Рухани Җирҗис чыга.
Бу кэрванны каршы алып
Сыйларга ул ашыга.

Әбу Талибкэ әйтә ул:
«Сез килгәндә бу якка
Башын иде бар агачлар,
Калмады һичбер таш та.

Пәйгамбәргэ генә алар

Участник №86



Шулай башларын ия.
Алма зурлыгы мөхерен
Китаптан беләм.»-дия.

Яхудләрнен явызлыгын
Белеп торганга курә
Мөхэммэдне (г.с) Мәккәгэ ул
Кайтар дип киңәш бирә.

Мөхэммәдне (г.с) хезмәтчеләр
Озатып кайтып китә…
…Рөсулуллаһ яшь чагында
Сарык көтуе көтә.

**2. Мөхэммәд (г.с) нең өйләнуе. Балалары. Хәдичәнен улеме.**

Мөхэммәднең ( г.с) гаделлеген
Әдәплелеген белеп.
Хөдичә атлы бай хатын
Рәсулуллаһны куреп
Ышаныпи тапшыра сәудәсен
Вәгъдә итеп кубрәк хак
Хезмәтче Мәйсәрә белән
Китә Шамга Рәсулуллаһ.

Мөхәммәд ( г.с) кайта әйләнеп
Куп кенә табыш туплап.
Хәдичәнең исе китэ
Йөри ул аны уйлап.

Хаклык, изгелек иясе
Олуг дип дәрәжәсе
Сөйләп бирә Хәдичәгә
Хезмәтче Мәйсәрәсе.

Куп кенә бай кешеләрнең
Кире кагып тәкъдимен.
Хәдичә сөйли дустына
Куңелендәге теләген.

Рәсул жибәрә димләргә
Ата ягы кардәшен.
Хәдичә инде ул чагында
Тутыра 40 яшен.

Өйләнгәндә Мөхәммәдкә ( г.с)
25 яшь тула.
Ул инде башка өйләнми
Хәдичә исән чакта.

Алты балалары була:
Касыйм, Зәйнәп, Рокайя.

Участник №86



Өмме Кулсум, Фатыйма, Габдуллаһ
Ибраһим дигән малае
Була башка хатыннан.
Изге Рамазан аенда
Вафат була Хәдичә (р.г).
Ана 65 яшь була,
Мөхәммәд ( г.с) 50 яшьтә.
Алты баласын индерә
Рәсулуллаһ гурләргә.
Аллаһ сабырлык биргәндер
Бу хәсрәткә түзәргә.

**3. Мөхәммәд ( г.с) кә вәхи иңүе.**

Пәйгамбәр гәләйһиссәлләмгә
Кырык яшьләр тулгач.
Кабиләләр арасында
Капма-каршылыклар тугач

Аулакта кала Мөхәммәд ( г.с)
Хира тавына килеп
Мескеннәрне туендыра
Аларга ризык биреп.

Уйлана ул бу галәмне
Бар кылучы турында.
Кабиләләр мөшриклеге
Тынгы бирми жанына.

Берничә тапкыр Хирага
Рәсул аулакка килә.
Жәбраил аша беренче
Аятьләр шунда иңә.

«Укы! Укы!»-ди Жәбраил
Укый белми Мөхәммәд( г.с)
Шуннан «Галәкъ» сурәсеннән
Иңә аңа 3 аять. («Галәкъ» сурәсе)

Мөхәммәд ( г.с) кайтып куркудан
Сөйләгәч Хәдичәгә (р.г)
Хәдичә аны юатып
Апасына жибәрә.

Вәрәка аңа аңлата
Фәрештәнең килуен.
Аллаһнын рәхмәте белән
Пәйгамбәрлек иңуен.

Пәйгамбәр гәләйһиссәлламгә
Вәхи бик озак килә.
23 ел буе аңа

Коръәни Кәрим иңә.

**4. Мөхәммәднең ( г.с) дәгъват чорлары. Яшерен һәм ачык дәгъваты. Гомәр һәм Хәмзәнең иман китерүе.**

Мөхәммәднең ( г.с) дәгъват чоры
Мәккәдә 13 ел була .
Мәдинәдәге дәгъваты
Ун елга төгәл тула.

Мәккә чорында 3 ел буе
Дәгъват яшерен була.
Исламны беренче булып
Хәдичә кабул кыла.

Дуслары да калышмыйлар,
Әбу Бәкер хөрмәтле.
Йомшак, гыйлемле бер дусты
Исламга ул өндәште.

Ышанычлы кешеләргә
Тәкъдим итеп Исламны.
Ләә иләәһә иллә-әл-лаһ дип
Рәсулуллаһ кушканны.

3 ел яшерен булган дәгъват
Уз төркемен булдыра.
Рәсулгә бер Аллаһыдан
Шуннан соң әмер була.

Потлардан арындырырга дип,
Кучеп ачык дәгъваткә. (Шугара сурәсе)
Якыннарын жыя рәсул
Дәгъвәт итеп кинәшкә.

Әбу Ләһәб, Әбу Жәһел
Гомәр белән Хәмзә дә
Бик нык каршы торучанлык
Мөхәммәдкә ( г.с) курсәтә.

Хәмзә Ислам динен беркөн
Кабул итә узе дә.
Әбу Жәһел Хәмзә улына
Мәсхәрәлек курсәтә.

Тузмәде ул туганының
Улын хурлауларына.
Аллаһы анын калебен
Ача ислам нурына.

Гомәр Исламга керсен дип
Пәйгамбәр кыла дога.

Участник №86



Анның күңеле бик озак
Икеле уйда була.

Пэйгамбәр намаз кылганын
Гомәр бер тыңлап тора.
Уңдырышлы туфракка
Орлык төшкәндэй була.

Кызулыгы, наданлыгы
Гел узенекен итэ.
Мөхәммәдне ( г.с) утерәм дип
Кылычын алып китә.

Тик ишетә кыз туганы
Ире белән берлектә.
Ислам диненә кучкәнен
һәм яннарына китә.

Өйлэренә якынлашкач
Ишетә гажәп сурә. («Таһа» сурэсе)
Канга батырып туганын,
Суга анын йөзенә.

Гомәрнең күңеле шунда
Оялу белән тула.
Тәһарәт алып сурәне
Узе дә укып чыга.

Анда язылган сузләргә
Гомәр хәйран кала.
Кылычын алып янәдән
Мөхәммәдкә ( г.с) ул бара.

Менә шулай кабул итә,
Ул Исламның нигезен.
Тырышлык куя дин юлында
Аямыйча ул узен.

Бу хәлдән соң мөселманнар
Бөеклеккә иреште.
Аллаһка иман китерә
Мөшрикләрнең кубесе.

**5. Дәгъват юлында очраган киртәләр. Мөхәммәд ( г.с) катнашындагы сугышлар.**

Аяк чалулар куп була
Мыскыллап көлуләр дә
Хурлау, гайбәт, куркытулар
Рухларын зәгыйфләу дә.

Мәсхәрәле яла ягып

Участник № 8 б



Женле дип сылтаулары
Сихерче, ялганчы, шагыйрь дип
Рәсулне атаулары.

Ялган фикерләр таратып
Кешегә коткы салу.
Мөхәммәд ( г.с) язган шигырь дип
Коръәнне ялганга чыгару…

… Тормыш юлын уткән чакта
Катнашу сугышларда
Хакны бидгатьтән аеру
Булганга соңгы чара.
Бәдер, Өхед сугышларын
Кичергән Рәсулуллаһ
Сакчы фәрештәләр белән
Саклаган аны Аллаһ.
Хәйбәр, Мут, Таиф, Мәккә
һәм башка куп сугышлар.
Мөселман халкын яклаганда
Булган куп кан коешлар…

**6. Хаҗ кылу. Мөхәммәд ( г.с) нең вафаты.**

һиҗри белән унынчы ел
Пәйгамбәр хаҗын кыла.
Фәлестинга сәяхәте,
Иң соңгы поход була.

Шушы сәяхәт юлында
Авырый Рәсулуллаһ
«Наср» сурәсен индерә
Соңгысы итеп Аллаһ.

Хәм авыр булганда да
Гел бергә нәсыйхәтләр.
Намаз укыдылармы диеп
Борчыла хак Пәйгамбәр.

Унберенче хиҗри елда
Рабигыль –әувәл аенда.
Вафат була Рәсулуллаһ
Хәләле Гайшә йортында.

Рәсулуллаһнын улемен
Авыр кичерә халык
Бар Мәдинәне баскан кук
Шомлылык, караңгылык.

**7. Мөхәммәд ( г.с) нең тышкы һәм әчке матурлыгы.**

Йөзе нурлы, бик ягымлы

Участник № 86



Кушылган кыйгач кашлы
Озын керфек; колакларга
Бик ятышлы тавышы.
Матур сөйләм, ачык сузләр
Мәржән кебек тезелә.
Кешедән узен тыңлата,
Хөрмәт казана белә.
Буш сузләрне һич сөйләми
Кояш, айга тиңләнә.
Кыюлыгы аеруча
Риваять итеп сөйләнә.
Искиткеч сабыр була ул,
Сөйләмнәре мәгънәле
Ифрат батыр йөрәкле һәм.
һич тә курку белмәле.
Оялчанлыгы да булган
Инсафлы һәм дә тыйнак
Тәккәберлекне сөймәгән.
Аннан торган бик ерак.
Мөхэммэд ( г.с)  максатчан була.
Фикерләре акыллы.
Ырымнарны яратмаган
Сөйгән узе халыкны.
Кемнең ничек яшәгәнен
Бик әйбәт белеп торган
Уз тормышы кешеләрнең
Куз алларында булган
Яшәгән ул гел яхшылык,
Изге гамәлләр кылып.
Киресенчә булган чакта
Уйланган ялгыз калып.
Хөмердән бик ерак торган,
Өнәмәгән потларны.
Дөнья ләззәтеннән аны
Аллаһ узе коткарды.
Куркәм холык, камил әхлак
Юаш, гади, ярдәмчел
Йомшак, юмарт, бик кунакчыл
Гыйлемле һәм бик гадел.
Зәгыйфләрнең авыр йөген
Кайтарыша кутәреп.
Өйрәтә ул сабырлыкка
Сынауларны уткәреп.
Рәхим-шәфкатьле булган ул
Мескеннәргә булышкан.
Узен-узе аямыйча
Ислам өчен тырышкан.
Ихтирам иткән һәркемне
Бәрелмәгән һич каты.
һәрвакыт ул телгә алган
Хак булган бер Аллаһны
Сыйфатларын санап биру

Участник №86



Булмас иде hич мөмкин
Чонки аның эхлагында
Үзе Коръэни Кэрим.

**8. Мохэммэд ( г.с) нең доньялар тарихында тоткан урыны.**

Пэйгамбэр гэлэйhиссэлләмнең
Тормышы бай хэзинэ
Ул кичергэн вакыйгалар
Зур эhэмияткэ ия.
Рэсул кичергэн жэфалар,
Бэлалэр, авырлыклар
Беркемдэ юк андый күнел.
Олуглык, сабырлыклар.
Рэсулуллаh
Мохэммэд Мостафа ( г.с) белэн
Тиңлэшэ алмый hичкем.
Аның сүзлэрендэ хаклык,
Белсэк иде мэгънэсен.
Доньяларның тарихында
Ул тора үрнэк булып.
Топ чыганагы Коръэнгэ
Яшэсэк иде тотынып.
Дөрес яшэу рэвешлэре
Иманның арканнары.
Вакыйгаларга нигезле
Шэригать кануннары.
Хэдис, тэфсир китаплары,
Чыганагы тормышның.
Бу китапларда бэяне
Иман, тэкъдир, язмышның
Шушы китаплар аша бит
Саклана динем Ислам.
Хак юллардан тайпылмаска
Насыйп ит миңа Ходам

**9. Мохэммэд ( г.с) нең дэрэжэсе.**

Аллаhы хак илчесенең
Күтэрде исемен биек.
Ахирэттэ hэм доньяда
Зекер ителсен диеп.
Кем булуга карамастан,
Хотбэче, шэhэдэтче.
Намаз, Коръэн укучымы
Мэчеттэ гыйбадэтче
Аллаh белэн бергэ Аны
Бар кеше искэ ала.
Азан, камэтлэр янгырый,
Салават эйтеп кала.
Башка hичкем Рэсул кадэр

Участник № 86



Алынмый hичтэ искэ.
14 гасыр шулай булган
Булыр ул кыямэткэчэ.